ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 март 2018ел № 1631

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 нчы карары, Татарстан Республикасының «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ санлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 елның 23 апрелендәге 275 нче карары, Яр Чаллы шәһәре Уставы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ

регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4353 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ә. Кыямовка Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентын «Челнинские известия» газетасында бастыруны, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 27 мартындагы
1631 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламенты (алга таба – Административ регламент) муниципаль торак контролен (алга таба – муниципаль контроль) гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәгәндә административ процедуралар һәм административ гамәлләрнең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Муниципаль торак контроле Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы функциясе булып тора.

1.2. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы орган булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе йөзендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – муниципаль торак контроле органы) тора.

Муниципаль контроль муниципаль торак контроле органының бер үк вакытта муниципаль торак инспекторлары булып торган вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль функцияне үтәгәндә муниципаль торак контроле органының вазыйфаи затлары дәүләт торак күзәтчелеге органнары, суд органнары, хокук саклау органнары, прокуратура органнары, экспертлар һәм эксперт оешмалар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар белән үзара эшчәнлек алып бара.

1.3. Муниципаль функцияне үтәү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе («Российская газета», №237, 25.12.1993);

- Россия Федерациясе Торак кодексы, 29.12.2004 ел, №188-ФЗ («Собрание законодательства РФ», 03.01.2005, №1 (1 бүлек), ст. 14; «Российская газета», 12.01.2005, №1; «Парламентская газета», 15.01.2005, №7-8) (алга таба – РФ Торак кодексы);

- Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы

30.12.2001, №195-ФЗ («Российская газета», 31.12.2001, №256; «Парламентская газета», №2-5, 05.01.2002; «Собрание законодательства РФ», 07.01.2002, №1 (1 бүлек), ст. 1) (алга таба – РФ Административ хокук бозулар турында кодексы);

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 131-ФЗ санлы Федераль законы («Собрание законодательства РФ», 06.10.2003, №40, ст. 3822; «Парламентская газета», №186, 08.10.2003; «Российская газета», №202, 08.10.2003) (алга таба – 131-ФЗ санлы Федераль закон);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон («Российская газета», №266, 30.12.2008; «Собрание законодательства РФ», 29.12.2008, №52 (1 бүлек), ст. 6249; «Парламентская газета», № 90, 31.12.2008) (алга таба – 294-ФЗ санлы Федераль закон);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 нчы карары («Собрание законодательства РФ», 12.07.2010, №28, ст. 3706) (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 нчы Карары);

- Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче Приказы («Российская газета», №85, 14.05.2009) (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының №141 нче приказы);

- Татарстан Республикасының «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ санлы Законы («Ватаным Татарстан», №201-203, 19.10.2011; «Республика Татарстан», №201, 21.10.2011; Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Җыелма басмасы, №10 (I бүлек), октябрь 2011) (алга таба – ТР №72-ТРЗ санлы Законы);

- «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы («Челнинские известия», №235-237, 10.12.2005, «Челнинские известия», №249-250, 30.12.2005) (алга таба – шәһәр Уставы).

1.4. Муниципаль торак контроленең предметы булып юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар тарафыннан торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар белән муниципаль торак фондына карата билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәү тора.

1.5. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда вазыйфаи затларның хокулары һәм бурычлары.

1.5.1.Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

- дәлилләнгән язмача запрослар нигезендә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, физик затлардан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны сорарга һәм алырга;

- хезмәткәр таныклыгын һәм муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең тикшерү билгеләү турында боерыгы күчермәсен күрсәтеп, территориягә һәм анда урнашкан күп фатирлы йортларга, наемга алынган социаль файдаланудагы йортларга, күп фатирлы йортлардагы гомуми файдаланудагы бүлмәләргә тоткарлыксыз керергә; күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләренең ризалыгы буенча торак бүлмәләргә керергә һәм аларны тикшерергә; тикшерүләр, сынаулар, тикшеренүләр, экспертизалар һәм контроль буенча башка чаралар үткәрергә, наемга алынган социаль файдаланудагы йортларда торак бүлмәләрне наемга бирүчеләр тарафыннан шундый йортларны наемга бирүчеләргә һәм наемга алучыларга, социаль файдаланудагы торак фондның торак бүлмәләрен наемга алу килешүләре һәм торак бүлмәләрне наемга алу килешүләре бәяләмәсенә һәм үтәлешенә карата куелган мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен, РФ Торак кодексының 91.18 маддәсенең 2 бүлеге нигезендә каралган затлар тарафыннан наемга алынган социаль файдаланудагы йортларны муниципаль реестрда исәпкә алу өчен кирәкле мәгълүматларны раслаучы документларны тапшыруга карата куелган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә; торак милекчеләре ширкәтләренең, торак, торак-төзелеш һәм башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларының уставларының, шундый ширкәтнең яки кооперативның уставына кертелгән үзгәрешләрнең Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүен тикшерергә; күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләренең гаризалары буенча, күп фатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми җыелышында торак милекчеләре ширкәте төзү турында карар кабул итүнең нигезле булуын, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышында торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы идарәсен сайлауның нигезле булуын, торак милекчеләре ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышында яки торак милекчеләре ширкәте идарәсе тарафыннан шундый ширкәтнең идарә рәисен сайлауның нигезле булуын, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы идарәсе тарафыннан шундый кооперативның идарә рәисен сайлауның нигезле булуын, күп фатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми җыелышында, РФ Торак кодексының 162 маддәсе нигезендә күп фатирлы йорт белән идарә итү килешүе төзү максатында идарәче оешманы сайлау турында карар кабул итүнең нигезле булуын, әлеге килешүнең һәм аны төзү шартларын раслауның нигезле булуын, идарәче оешма белән күп фатирлы йорттагы гомуми милкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр

күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару килешүе төзүнең нигезле булуын, РФ Торак кодексының 164 маддәсенең 1 бүлегендә күрсәтелгән затлар белән күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару килешүе төзүнең нигезле булуын, әлеге килешүләрнең шартларын раслауның нигезле булуын тикшерергә;

- мәҗбүри таләпләрне бозуны туктату, ачыкланган кимчелекләрне бетерү, мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар үткәрү турында, шул исәптән торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставының мәҗбүри таләпләргә кертелгән үзгәрешләргә туры килмәгән андый күрсәтмәне җибәргән көннән башлап алты айлык срокта бетерү турында күрсәтмә бирергә;

- мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм андый кимчелекләрне булдырмый калу буенча чаралар күрергә;

- мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле материалларны, җинаять билгеләре буенча җинаять эше кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрергә.

1.5.2. Муниципаль торак контроле органы түбәндәге гаризалар белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

- күп фатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми җыелышында яисә торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышында РФ Торак кодексы таләпләрен бозып кабул ителгән карарларны гамәлдән чыккан дип тану турында;

- андый торак милекчеләре ширкәте яки андый кооператив уставына кертелгән үзгәрешләрнең РФ Торак кодексы таләпләрендәге үзгәрешләргә туры килмәвен бетерү турындагы күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәү очрагында яисә андый ширкәт яки андый кооператив төзү тәртибендә кимчелекләр ачыкланган очракта, әгәр әлеге кимчелекләр төзәтелмәслек характерда булса, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын бетерү турында;

- идарә оешмасын сайлау, күп фатирлы йорт белән идарә итү килешүе шартларын раслау һәм аны төзү, хезмәт күрсәтү һәм (яки) күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту буенча эшләр башкару һәм ремонтлау килешүен яисә күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту һәм (яки) ремонтлау буенча эшләр башкару килешүен төзү, күрсәтелгән килешүләрнең шартларын раслау турында РФ Торак кодексының таләпләрен бозуны бетерү турындагы күрсәтмә билгеләнгән срокта үтәлмәгән очракта, күп фатирлы йорт белән идарә итү килешүен, хезмәт күрсәтү һәм (яки) күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту буенча эшләр башкару һәм ремонтлау килешүен яисә күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту һәм (яки) ремонтлау буенча эшләр

башкару килешүен гамәлдән чыккан дип тану турында;

- мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, торак милекчеләренең, наемга алучыларның һәм аннан башка файдаланучыларның мөрәҗәгатьләре буенча аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау яки билгеле булмаган даирә затларының хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен;

- социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын наемга алу килешүенең РФ Торак кодексында билгеләнгән таләпләргә туры килмәвен бетерү турындагы күрсәтмә тиешле срокта үтәлмәгән очракта, әлеге килешүне гамәлдән чыккан дип тану турында.

1.5.3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда вазыйфаи затларның бурычлары:

- Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәү;

- Россия Федерациясе законнарын, тикшерелә торган юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, физик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау;

- муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең боерыклары нигезендә тикшерүне аны билгеләүгә туры китереп үткәрү;

- тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын үтәгән вакытта гына, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныклыгын, муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең боерык күчермәсен күрсәтеп кенә уткәрү, 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсе 5 бүлегендә каралган очракта, тикшеру үткәрүне килешенү турында документ күчермәсен күрсәтү;

- җитәкчегә, башка вазыйфаи затка, юридик зат вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, физик затка, аның вәкаләтле вәкиленә комачаулык итмәү, тикшерү үткәргәндә катнашу һәм тикшерү предметына караган сорауларга аңлатмалар бирү;

- тикшерү үткәргәндә катнашкан җитәкчегә, башка вазыйфаи затка, юридик зат вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, физик затка, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүматлар һәм документлар бирү;

- җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, физик затны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;

- җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, физик затны, аның вәкаләтле вәкилен мәгълүмати ведомствоара эшчәнлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән таныштыру;

- ачыкланган кимчелек фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә, күрсәтелгән чараларның кимчелекләрнең авырлык дәрәҗәсенә туры килүен, аларның кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе

халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуның потенциал куркынычлылыгын исәпкә алу, шулай ук гражданнарның, шул исәптән юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймау;

- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар тарафыннан шикаять бирелгәндә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үз эшләренең нигезлелеген исбатлау;

- тикшерү үткәрүнең 294-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән срокларын үтәү;

- юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, физик затлардан Россия Федерациясе законнарында каралмаган документларны һәм башка мәгълүматларны бирүне таләп итмәү;

- күчмә тикшерү башланыр алдыннан җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, физик зат, аның вәкаләтле вәкиленең үтенече буенча тикшерү шуның нигезендә үткәрелә торган административ регламентның нигезләмәләре белән таныштыру;

- юридик затта, шәхси эшмәкәрдә тикшерүләр журналы булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында андый журналда язып кую.

1.5.4. Тикшерү үткәргәндә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыра торган вазыйфаи затларның түбәндәгеләргә хокуклары юк:

- мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тикшерү, әгәр андый таләпләр муниципаль торак контроле органы исеменнән эш итүче әлеге вазыйфаи затларның вәкаләтләренә кермәсә;

- СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне үтәүне, шулай ук Россия Федерациясе законнарында мәҗбүри куллану каралмаган норматив документларның таләпләрен үтәүне тикшерү;

- мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне, Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә бастырып чыгарылмаган таләпләрне үтәүне тикшерү;

- планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыру, әгәр җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, физик зат, аның вәкиле тикшерүдә катнашмаган очракта, әгәр андый тикшерү 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсе 2 бүлеге 2 пунктының «б» пунктчасында каралган нигездә үткәрелгән очрактан тыш, шулай ук җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир хуҗаларына һәм җир

кишәрлекләре арендаторларына тиешенчә хәбәр җиткергән очракта, җир законнары таләпләрен үтәүне тикшерү;

- тикшерү объектлары булып саналмаган яки тикшерү предметына карамаган документларны, мәгълүматны, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм производство объектларын тикшерү пробаларын тапшыруны таләп итмәү, шулай ук андый документларның төп нөсхәләрен куллануддан алу;

- илкүләм стандартлар, үрнәкләр, пробалар сайлап алу кагыйдәләре һәм аларны тикшерү, сынау, үлчәү методлары, техник регламентлар яки аларның үз көченә керү көненә кадәрге башка норматив техник документлар һәм тикшерү, сынау, үлчәү методлары һәм кагыйдәләре белән билгеләнгән нормалардан артып киткән һәм билгеләнгән форма буенча күрсәтелгән үрнәкләрне, пробаларны сайлап алу турында беркетмәләр рәсмиләштермичә, аларны тикшерү, сынау, үлчәүне үткәрү өчен әйләнә-тирә мохит объектларын һәм производство объектларын тикшерү пробаларын, продукция үрнәкләрен алу;

- тикшерү үткәрү нәтиҗәләрендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт буенча һәм башка закон белән саклана торган сер булган (Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш) мәгълүматны тарату;

- тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттыру;

- юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга алар хисабына контроль буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашыру;

- юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, физик затлардан, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә ведомстводагы дәүләт органнары яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан аерым исемлеккә кертелгән оешмаларның җирле үзидарә органнары карамагындагы рөхсәт бирү документларын да кертеп, документлар һәм (яки) мәгълүматлар таләп итү;

- юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, физик заттан тикшерү үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар таләп итү. Муниципаль торак контроле органы тикшерү үткәрү турында боерык кабул ителгәннән соң ведомствоара үзара эшчәнлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

1.6. Муниципаль торак контроле буенча чаралар гамәлгә ашырылуга мөнәсәбәтле затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.6.1. Тикшерү үткәргәндә җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, физик зат, аның вәкиле түбәндәгеләргә хокуклы:

- тикшерү үткәргәндә турыдан-туры катнашу, тикшерү предметына караган сорауларга җаваплар бирү;

- муниципаль торак контроле органыннан, аның вазыйфаи затларыннан 294-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә тикшерү предметына караган мәгълүматны алу;

- муниципаль торак контроле органыннан, ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат алар карамагында булган ведомстводагы оешмаларның дәүләт органнарыннан яки җирле үзидарә органнарыннан алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышу;

- ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында соратылган документлар һәм (яки) мәгълүматларны муниципаль торак контроле органына үз инициативасы белән бирү;

- тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзеңнең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуың, алар белән, шулай ук муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының аерым эш итүләре белән килешүең яки килешмәвең турында күрсәтү;

- муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның хокукларын бозуга китергән эш итүләрен (эш итмәүләрен) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять итү;

- Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтлене яисә Россия Федерациясе субъектындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтлене тикшерүдә катнашуга җәлеп итү.

Муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының эш итүләре (эш итмәүләре) нәтиҗәсендә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга китерелгән зыян, әгәр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртип нигезендә хокуксыз дип танылса, гражданлык законнарына туры китереп, ул алынмый калган файданы да кертеп (алынмаган калган керемне), бюджет средстволары хисабына кире кайтарып алынырга тиеш.

Муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының хокуксыз эш итүләре нәтиҗәсендә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга китерелгән зыян, федераль законнар белән каралган очрактан тыш, кире кайтарып алынмый.

1.6.2. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиле, физик зат яки аның вәкиле тикшерү барганда түбәндәгеләргә бурычлы:

- муниципаль торак инспекторларының дәлилләнгән язма рәвешендәге запрослары нигезендә, мәҗбүри таләпләрне үтәүне тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны бирү;

- күчмә тикшерү үткәрүче муниципаль торак инспекторларына һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларга, эксперт оешмалары вәкилләренә территорияләргә һәм анда урнашкан күп фатирлы йортларга, күп фатирлы йортларның эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган гомуми файдаланудагы торак урыннарына тоткарлыксыз керүне тәэмин итү;

- компетенция чикләрендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны туктату, ачыкланган кимчелекләрне бетерү, мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү

буенча чаралар үткәрү турында муниципаль торак инспекторлары биргән күрсәтмәләрне билгеләнгән срокта үтәү;

- административ хокук бозуларга китергән шартларны һәм сәбәпләрне бетерү.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле шулай ук күчмә тикшерү үткәрүче муниципаль торак инспекторларына һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларга, эксперт оешмалары вәкилләренә территорияләргә һәм андагы юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда файдалана торган биналар, төзелешләр, корылмалар, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүне тәэмин итү.

Тикшерүләр үткәргәндә юридик затлар җитәкчеләрнең, башка вазыйфаи затларның яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләренең катнашуларын тәэмин итәргә бурычлы; шәхси эшмәкәрләр катнашырга яки мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә бурычлы.

Тикшерүләр үткәргәндә физик затлар катнашырга яки аларның вәкаләтле вәкилләренең катнашуын тәэмин итәргә бурычлы.

1.6.3. Муниципаль торак контроле буенча чаралар үткәрүгә комачаулык итүче затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

1.7. Муниципаль функцияләрне үтәү нәтиҗәләрен тасвирлау.

Тикшерү үткәрә торган муниципаль торак контроле органының вазыйфаи затлары планлы, планнан тыш тикшерүләр үткәрү нәтиҗәләре буенча түбәндәге документларны төзиләр:

- юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, физик затларның әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасында каралган формада 2 данәдә тутырылган, анда торак законнары таләпләрен бозу ачыкланган билгеләр булу яисә андый кимчелекләрнең булмавын күрсәткән (тикшерү актының типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче приказы белән билгеләнгән) торак законнарын үтәүне тикшерү акты;

- кимчелекләр ачыкланган очракта – мәҗбүри таләпләрне бозуны туктату, әлеге Административ регламентның 4 нче кушымтасы нигезендә мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр бирү;

- кимчелекләр ачыкланган очракта – муниципаль торак контроле органының компетенциясе чикләрендә законда каралган административ хокук бозулар турында беркетмә;

- үткәрелгән күчмә тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналына язып кую, андый журнал булса (тикшерүләрне исәпкә алу журналының типовой формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче приказы белән расланган).

Күчмә тикшерү үткәрүче муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының тикшерелә торган затның территориясенә яки

бинасына керүенә комачаулык булганда, әлеге Административ регламентның 2 нче кушымтасында каралган форма буенча акт төзелә. Акт муниципаль торак контроле органының вазыйфаи затлары һәм тикшерелә торган зат яки вәкаләтле вәкил тарафыннан имзалана. Баш тарту очрагында актта тиешле язу языла.

Торак законнары таләпләрен бозу ачыкланган очракта, аның өчен Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ яки башка җаваплылык каралган, тикшерү (тикшереп чыгу) акты, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә чара күрү өчен, дәүләт торак күзәтчелеге органына һәм башка күзәтчелек һәм контроль органнарына җибәрелә.

1.8. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү.

1.8.1. Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, физик затларның мәҗбүри таләпләрне бозуларын кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуларга китергән сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатында, муниципаль торак контроле органы мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын кимчелекләрне профилактикалауның ел саен төзелә торган программасы нигезендә гамәлгә ашыра.

1.8.2. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау максатында муниципаль торак контроле органы түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) норматив хокукый актлар исемлеген яки аларның муниципаль торак контроленең предметы саналган мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү булган аерым бүлекләрен, шулай ук норматив хокукый актларга туры килгән текстларны «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштыруны тәэмин итә;

2) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат җиткерүне, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү, семинарлар һәм конференцияләр буенча җитәкчелек итү материалларын әзерләү һәм бастырып чыгару юлы белән, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре алып бару һәм башка алымнар белән гамәлгә ашыра. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта, муниципаль торак контроле органы, мәҗбүри таләпләрне билгеләүче, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның гамәлгә керү сроклары һәм тәртибе, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәүне гамәлгә кертү һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру һәм техник чаралар үткәрү турындагы тәкъдимнәр булган яңа норматив хокукый актларны әзерли һәм аларның эчтәлеге турында комментарийлар тарата;

3) муниципаль торак контроле эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә гамәлгә ашыру практикасын регуляр рәвештә (елына 1 тапкырдан ким түгел) гомумиләштерүне тәэмин итә һәм тиешле гомумиләштерүләрне, мәҗбүри таләпләрне еш бозган очракларны, андый бозуларны булдырмау максатында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар тарафыннан аларга карата күрелергә тиешле чаралар турындагы тәкъдимнәрен күрсәтеп

«Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштыра;

4) әгәр федераль законда башка тәртип билгеләнмәгән булса, 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.2 маддәсе 5-7 бүлекләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуны булдырмау турында кисәтү бирәләр.

1.8.3. Әгәр башкасы федераль законда билгеләнмәгән булса, муниципаль торак контроле органында мәҗбүри таләпләрне бозарга әзерләнү яки бозу билгеләре турында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар белән үзара эшләмәүне гамәлгә ашыруга контроль буенча чараларны тормышка ашыру барышында алынган мәгълүматлар булса яисә алынган мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалардан тыш) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларда әгәр мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозу кеше тормышына, гражданнар сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт куркынычсызлыгына зыян салса, шулай ук табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерсә яисә турыдан-туры куркыныч тудырса, һәм әгәр юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат әлеге таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган булсалар, муниципаль торак контроле юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау кирәклеге турында кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә, һәм бу хакта мондый кисәтү ясаганда билгеләнгән срокта муниципаль торак контроле органына хәбәр җиткерергә тәкъдим итәләр.

1.9. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара эш итмәүгә контроль буенча чаралар оештыру һәм үткәрү.

1.9.1. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара эш итмәүгә контроль буенча чаралар муниципаль торак контроле органының вазыйфаи затлары белән үз компетенцияләре чикләрендә андый чаралар үткәрүгә муниципаль торак контроле органы җитәкчесе тарафыннан расланган йөкләмәләр нигезендә үткәрелә.

1.9.2. Контроль буенча чаралар муниципаль торак контроле органының юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара эш итүе соралмаганда, контроль буенча чараларга (алга таба – юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара эш итмәүгә контроль буенча чаралар) түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә электроэнергетика, газ белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су бирү челтәрләре һәм объектларының эшләү параметрларын үлчәү;

2) «Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырганда мәҗбүри таләпләрне үтәүне күзәтү;

3) эшчәнлек турындагы мәгълүматны яисә бурычлары федераль закон

нигезендә йөкләтелгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләрнең эш итүләрен анализлау юлы белән (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану аша) мәҗбүри таләпләрне үтәүне күзәтү;

1.9.3. 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.3 маддәсе 1 бүлегендә күрсәтелгән контроль буенча чаралар үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, муниципаль торак контроле органының вазыйфаи затлары үз компетенцияләре чикләрендә андый кимчелекләрне туктату буенча чаралар күрәләр, шулай ук муниципаль торак контроле органы җитәкчесенә язмача рәвештә ачыкланган кимчелекләр, кирәкле карарны кабул итү өчен 294-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсе 2 бүлеге 2 пунктында күрсәтелгән нигездә юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш тикшерү билгеләү турындагы дәлилләнгән мәгълүмат җибәрәләр.

1.9.4. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар белән үзара эшләмәүне гамәлгә ашыруга контроль буенча чаралар үткәрү барышында 294-ФЗ санлы Федераль законның 8.2 маддәсе 5-7 бүлекләрендә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләрне бозарга әзерләнү яки бозу билгеләре турында мәгълүматлар алынган очракта, муниципаль торак контроле органы юридик затка, шәхси эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү җибәрә.

## 2 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне гамәлгә ашыру тәртибенә таләпләр

2.1. Муниципаль функцияләрне үтәү турында мәгълүмат бирү тәртибе.

2.1.1. Муниципаль торак контроле органының урнашкан урыны: 423805, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 (414, 415 нче кабинетлар).

2.1.2. Муниципаль торак контроле органының эш графигы:

| | |
|---|---|
| Дүшәмбе – җомга | 8.00 - 1 7.00 |
| Төшке аш вакыты | 12.00 - 13.00 |
| Шимбә, якшәмбе | ял көне |

2.1.3. Муниципаль торак контроле органының белешмә телефоннары: (8552) 30-55-57, 30-59-55, 30-59-52.

2.1.4. Муниципаль торак контроле органының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты: www.nabchelny.ru (алга таба – рәсми сайт);

Мөрәҗәгать җибәрү өчен Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге электрон почта адресы: kr415@mail.ru (алга таба – электрон почта адресы).

Муниципаль функцияләрне үтәү мәсьәләләре буенча муниципаль торак контроле органына документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 423805, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23.

2.1.5. Муниципаль функцияләрне үтәү урыны:

- документар тикшерү вакытында – муниципаль торак контроле органының урнашкан урыны буенча;

- күчмә тикшерү үткәргәндә – юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структура бүлекчәләренең) урнашкан урыны буенча, шәхси эшмәкәрләрнең яшәү урыны һәм аларның факттагы эшчәнлек алып бару урыны буенча, физик затларның яшәү урыны буенча.

2.1.6. Муниципаль функцияләрне үтәү тәртибе турындагы мәгълүмат муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручылар тарафыннан түбәндәгечә бирелә:

- турыдан-туры шәхси кабул итү кысаларында;

- язмача рәвештә (почта аша мөрәҗәгать иткәндә әлеге Административ регламентның 2.1.4 пунктында күрсәтелгән реквизитлар буенча);

- мөрәҗәгать итүченең электрон почтасы аша.

Муниципаль функцияләрне үтәү тәртибе турындагы мәгълүмат муниципаль торак контроле органының рәсми сайтында урнаштырыла һәм яңартыла (әлеге Административ регламентка үзгәрешләр кертүгә карап).

2.2. Муниципаль торак контроле буенча чаралар үткәрү өчен юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм физик затлардан акча алуга юл куелмый.

Муниципаль торак контроле буенча чаралар үткәрү өчен, шул исәптән тикшерүләр үткәрүгә җәлеп ителгән экспертлар һәм эксперт оешмаларның хезмәтләре өчен юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм физик затлардан акча алынмый.

2.3. Муниципаль функцияләрне үтәү срогы.

Документар тикшерү (планлы һәм планнан тыш), күчмә тикшерү үткәрү (планлы һәм планнан тыш) срогы 20 эш көненнән артмаска тиеш.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына – 50 сәгать, микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артмаска тиеш.

Тикшерү үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек кысаларында документлар һәм мәгълүмат алу кирәк булган очракта, тикшерү үткәрү муниципаль торак контроле органы җитәкчесе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка туктатып торылырга мөмкин, ләкин ун эш көненнән дә артык булмаска тиеш. Тикшерү үткәрүне кабаттан туктатып торырга ярамый.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда

территориядә, биналарда, төзелешләрдә, корылмаларда, башка кече эшмәкәрлек субъекты объектларында муниципаль торак контроле органының әлеге тикшерүгә бәйле эшләре туктатып торыла.

Искәрмә очракларда, планлы күчмә тикшерү үткәрә торган муниципаль торак контроле органы вәкаләтле затларының дәлилле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү кирәклеге белән бәйле булганда, планлы күчмә тикшерү үткәрү срогы шундый орган тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин ул 20 эш көненнән дә артык була алмый, кече предприятиеләргә карата – 50 сәгатьтән, микропредприятиеләр өчен 15 сәгатьтән дә артык түгел.

Үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасының берничә муниципаль берәмлегендә гамәлгә ашыра торган юридик затларга карата тикшерү үткәрү (документар да, күчмә дә) срогы юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структура бүлекчәсе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерү үткәрү срогы алтмыш эш көненнән дә артык булырга тиеш түгел.

2.4. Муниципаль торак контроле буенча чаралар планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы нигезендә үткәрелә торган планлы тикшерүләр формасында, шулай ук оешмаларның һәм физик затларның закон нигезендәге хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәп планнан тыш тикшерүләр формасында гамәлгә ашырыла.

2.5. Тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр.

2.5.1. Планлы тикшерүләр муниципаль торак контроле органының вазыйфаларына туры китереп төзелгән һәм расланган, еллык планнар (алга таба – План) нигезендә үткәрелә.

Планлы тикшерүнең предметы булып юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның эшчәнлек алып бару процессында мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүләрен тикшерү тора.

Еллык тикшерүләр планына кертү өчен түбәндәгеләрдән бер ел үткән булу нигез булып санала:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның күп фатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлеге һәм дәүләт торак күзәтчелеге органына әлеге эшчәнлекне башлау турында бирелгән белдерү кәгазе нигезендә хезмәт күрсәтү һәм (яки) күп фатирлы йортларның гомуми мөлкәтен карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр башкара башлаудан соң;

2) торак бүлмәләрне наемга бирүче, эшчәнлеге тикшерелә торган зат социаль файдаланудагы беренче наемга алынган йортны социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә куюдан соң;

3) юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны соңгы планлы тикшерү үткәрү тәмамланганнан соң;

4) коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр) куллану нормативларын билгеләгән яки үзгәрткәннән соң.

294-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Планда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) планлы тикшерү үткәрелә торган юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) исемнәре, шәхси эшмәкәрләр, гражданнарның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан урыннары яки шәхси эшмәкәрләрнең факттагы эшчәнлек алып бару урыны, физик затның яшәү урыны;

2) һәр планлы тикшерү үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерү үткәрүнең башлану датасы һәм сроклары;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыра торган муниципаль торак контроле органының исеме;

5) дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль торак контроле органы тарафыннан планлы тикшерүне бергә үткәргәндә, андый тикшерүдә катнашучы барлык органнарның да исемнәре күрсәтелә.

Муниципаль торак контроле органы еллык план проектын планлы тикшерүләр үткәрүнең алдагы елына, 1 июньгә кадәрге срокта планлы тикшерүләр үткәрүнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт торак күзәтчелеге органына; планлы тикшерүләр үткәрүнең алдагы елына, 1 сентябрьгә кадәрге срокта планлы тикшерүләр үткәрүнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль торак контроле органы урнашкан прокуратура органына җибәрә.

Муниципаль торак контроле органы прокуратура органнары тәкъдимнәрен карый һәм аларны карау йомгаклары буенча еллык расланган планны планлы тикшерүләр үткәрүнең алдагы елына, 1 ноябрьгә кадәрге срокта прокуратура органына җибәрә.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан раслана.

Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы кызыксынган затлар игътибарына аны муниципаль торак контроле органының www.nabchelny.ru рәсми сайтына урнаштыру яки башка уңайлы ысул аша җиткерелә.

Тикшерүләр үткәрүнең еллык планына үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 нчы карарындагы нормалар һәм таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка тикшерү башланганчы өч эш көненнән дә соңармыйча, муниципаль торак контроле органы тарафыннан, планлы тикшерү башлану турында муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең боерыгы күчермәсе, белдерү кәгазе бирү шарты белән, заказлы хат белән почта аша һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган

электрон документ итеп юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның электрон адресына җибәрелә, әгәр андый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса яисә муниципаль торак контроле органына юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элек башка төрле уңайлы ысул белән җибәрелгән булса.

Планлы тикшерү документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү рәвешендә үткәрелә.

2.5.2. Муниципаль торак контролен оештыру һәм үткәрү тәртибе булып, муниципаль торак контроле органының вазыйфаи заты тарафыннан планлы тикшерү үткәргәндә тикшерү кәгазьләрен файдалану бурычы (контроль сораулар исемлеге) күздә тотылырга мөмкин.

Тикшерү кәгазен (контроль сораулар исемлеген) кулланып тикшерү үткәргәндә, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) әлеге Административ регламентның 5 нче кушымтасында каралган тикшерү актына теркәлә.

2.5.3. Планнан тыш тикшерү үткәрү предметы булып, юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру процессында мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәү, муниципаль торак контроле органы күрсәтмәләрен үтәү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны булдырмау, андый зыян килү нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар үткәрү тора.

Планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәүдә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында элек бирелгән күрсәтмәне үтәү срогы чыгу;

2) муниципаль торак контроле органына юридик заттан яки шәхси эшмәкәрдән аерым эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга хокукый статус, башка юридик әһәмиятле эшне гамәлгә ашыруга махсус рөхсәт (лицензия) яки рөхсәт бирү (килешенү) алыну турында гариза керү, әгәр юридик затны, шәхси эшмәкәрне тиешле планнан тыш тикшерү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия), рөхсәт бирү (килешенү) кагыйдәләрендә каралган булса;

3) муниципаль торак контроле органнарына юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең үзара эш итмәүләрен контрольдә тоту буенча чаралар нәтиҗәләрен анализлау, муниципаль торак контроле органына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны карау яки алдан

тикшерү йомгаклары буенча муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затының, шул исәптән юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында дәлилләнгән мәгълүмат тапшыру:

а) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

в) кулланучыларның хокуклары бозылу (кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыра торган органга хокуклары бозылган гражданнарның мөрәҗәгать итү очрагында, әгәр гариза бирүче үзенең бозылган хокукларын яклауны (торгызуны) сорап юридик затка, шәхси эшмәкәргә мөрәҗәгать иткән булса һәм андый мөрәҗәгать карап тикшерелмәгән булса яисә мөрәҗәгать итүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгән булса);

4) Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы җитәкчесенең Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре һәм прокурор таләбе нигезендә, прокуратура органына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча закон үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында чыгарылган приказы (боерыгы).

5) муниципаль торак контроле органына нигездә торак-коммуналь хуҗалыгының мәгълүмат системасы аша гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан алынган мәгълүматлар, муниципаль торак контроле органының мәгълүмат системасында милекчеләргә һәм күп фатирлы йортлар һәм торак йортларның бүлмәләреннән файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, хезмәт күрсәтүне туктату һәм чикләү кагыйдәләре таләпләрен, торак милекчеләре ширкәтен, торак, торак-төзелеш яки махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы төзү тәртибенә таләпләрне, торак милекчеләре

ширкәтен, торак, торак-төзелеш яки махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставына таләпләрне һәм андый ширкәт яки андый кооператив уставына үзгәрешләр кертү тәртибенә таләпләрне, күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләренең, күп фатирлы йорт белән идарә итү буенча идарәче оешма белән килешү төзү максатында күп фатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыра торган, оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, юридик затны яки шәхси эшмәкәрне сайлавына таләпләрне, идарәче оешма белән хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) күп фатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм (яки) ремонтлау буенча эшләр башкару турында килешү төзү турындагы карарга таләпләрне, әлеге затлар белән РФ Торак кодексының 164 маддәсе 1 бүлегендә күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) күп фатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм (яки) ремонтлау буенча эшләр башкару буенча төзелгән килешүләр турындагы таләпләрне, әлеге килешүләрнең шартларын раслау һәм аларны төзү тәртибенә таләпләрне, күп фатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтне карап тоту һәм әлеге йорттагы гомуми мөлкәтне агымдагы һәм капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру тәртибенә таләпләрне бозу фактларын ачыклавы, идарәче оешмаларның РФ Торак кодексының 162 маддәсе 2 бүлегендә каралган йөкләмәләрне бозу фактлары турында, коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар кертә торган түләүләрнең чик (максималь) күләмен куллану өлкәсендәге кимчелек фактлары турында, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллануның билгеләнгән норматив күләменең нигезсез булуы, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативлары составына таләпләрнең бозылуы, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларының шартларын һәм билгеләү ысулларын үтәмәү, күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм торак бүлмәләрне карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу, социаль файдаланудагы наемлы йортлардагы торак бүлмәләрне наемга бирүчеләрнең андый йортлардагы торак бүлмәләрне наемга бирүчеләр һәм наемга алучыларга булган мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында, социаль файдаланудагы торак фонды бүлмәләренең наем килешүләрен һәм торак бүлмәләрнең наем килешүләрен төзү һәм үтәүнең бозылу фактлары турында, җирле үзидарә органнары, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күп фатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы затлар, гражданнар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләрне бозу фактлары турында кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар.

Муниципаль торак контроле органы тарафыннан планнан тыш тикшерү үткәрү өчен (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан җирле үзидарә органнарының вәкаләтле органнарына лицензияле контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән очракларда), Россия Федерациясе баш дәүләт торак инспекторының Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә

планнан тыш тикшерүне билгеләү турындагы приказы (боерыгы) нигез булып тора.

Муниципаль торак контроле органына мөрәҗәгать итүче затны ачыклау мөмкинлеге булмаган, шулай ук әлеге Административ регламентның 2.5.3 пункты 3 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматлар булган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып саналмый. Әлеге Административ регламентның 2.5.3 пункты 3 пунктчасы нигезендә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып саналмаган очракта, муниципаль торак контроле органының вазыйфаи заты, әгәр аңарда мөрәҗәгать яки гаризаның авторлыгында нигезле шикләнүләр булса, мөрәҗәгать иткән затны ачыклау өчен ул тиешле чаралар күрергә тиеш. Мөрәҗәгать итүченең электрон документлар рәвешендә җибәргән мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары планнан тыш тикшерү үткәрү өчен шул очракта нигез булып санала, әгәр алар гариза бирүче тарафыннан аның бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мәҗбүри авторизацияне күздә тоткан мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып җибәрелгән булса.

Мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, әлеге Административ регламентның 2.5.3 пунктында күрсәтелгән фактлар турындагы мәгълүматны караганда, элек кергән шундый мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны карау нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга карата контроль буенча элек үткәрелгән чараларның нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат булмаганда, мәҗбүри таләпләрне бозу турында яисә әлеге Административ регламентның 2.5.3 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүмат булмаганда, муниципаль торак контроле органының вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан кергән мәгълүматны алдан тикшерү үткәрелә. Алдан тикшерү үткәрү барышында, гариза һәм мөрәҗәгать җибәргән, мәгълүмат биргән затлардан өстәмә мәгълүматлар һәм материаллар соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, физик затларның муниципаль торак контроле органы карамагында булган документларын карап тикшерү үткәрелә, кирәк булганда, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, физик затларның бергә эш итмәүләрен һәм әлеге затларга мәгълүмат бирү буенча вазыйфаларын һәм муниципаль торак контроле органы таләпләрен үтәү һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча чаралар үткәрелә. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны алдан тикшерү кысаларында, алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, ләкин андый аңлатмалар һәм башка документларны бирү мәҗбүри түгел.

Муниципаль торак контроле органы җитәкчесе карары буенча, тиешле тикшерү башланганнан соң аны оештыруга сәбәп булган мөрәҗәгать яки гаризаның аноним булуы, яисә мөрәҗәгать яки гаризада дөрес булмаган мәгълүматлар барлыгы ачыкланса, ул чагында алдан тикшерү, планнан тыш

тикшерү туктатыла.

Әгәр гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә ялган мәгълүматлар күрсәтелгән булса, муниципаль торак контроле органы муниципаль торак контроле органының граждапнан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән күрсәтелгән затларның гаризаларын һәм мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле чыгымнарын кайтарып алу турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Планнан тыш тикшерү 294-ФЗ санлы Федераль законның 11 һәм 12 маддәләре белән билгеләнгән тәртиптә документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

Муниципаль торак контроле органы тарафыннан юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү федераль законнарда билгеләнгән нигезләрдә, андый юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлек алып бару урыны буенча прокуратура органы белән килешенгәннән соң үткәрелә.

Муниципаль торак контроле органы җитәкчесе, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык имзалаган көнне, аны үткәрүне федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә килешенү максатында, муниципаль торак контроле органы юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек алып бару урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турындагы гаризаны тапшыра яисә белдерү кәгазе белән почта аша заказлы хат, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә (РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче санлы Приказы белән расланган типовой форма нигезендә рәсмиләштерелә). Әлеге гаризага муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсе һәм аны үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә торган документлар теркәлә.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зарар килү, шулай ук табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең бозылуы торса, андый кимчелекләр булу вакытына, кичекмәстән чаралар күрү кирәк булу сәбәпле, контроль буенча чаралар үткәрү турында прокуратура органы документларын 24 сәгать эчендә җибәрү турында прокуратура органнарына хәбәр итү юлы белән, муниципаль контроль органы кичектергесез планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә керешергә

хокуклы. Бу очракта прокурор яки аның урынбасары планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турындагы карарны тиешле документлар кергәннән соң кабул итә.

Прокурор яки аның урынбасарының планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турындагы яки аны үткәрүне килешенүне кире кагу турындагы карарыннан риза булмыйча, югарыдагы прокурорга яки судка шикаять бирелергә мөмкин.

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында, планнан тыш күчмә тикшерү әлеге Административ регламентның 2.5.3. пунктында күрсәтелгән нигездә үткәрелүдән тыш, юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка муниципаль торак контроле органы тарафыннан аны үткәрә башлауга 24 сәгатьтән ким булмаган вакыт эчендә, теләсә нинди юл белән хәбәр җибәрелә, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ аша юридик зат, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресына белдерү кәгазе җибәрү юлы белән, әгәр андый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элек муниципаль торак контроле органына җибәрелгән булса.

Әгәр юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зарар килсә яки табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкса яки килеп чыгу куркынычы булса, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү башлану турында хәбәр бирү соралмый.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик затның мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәүдә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турындагы күрсәтмәне үтәү сроклары чыккан булу нигез булып торса, муниципаль торак контроле органы биргән күрсәтмәне үтәү генә андый тикшерүнең предметы булып тора ала.

2.6. Муниципаль торак контроле үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар.

Муниципаль торак контроле органының муниципаль торак контроле үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге

| Муниципаль торак контроле органы исеме | Вазыйфа исеме |
|---|---|

| | |
|---|---|
| Шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Идарә башлыгы<br>Идарә башлыгы урынбасары, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү бүлеге башлыгы<br>Идарә башлыгы урынбасары, икътисадый анализ һәм прогнозлау бүлеге башлыгы<br>Энергетика бүлеге башлыгы<br>Торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү бүлегенең баш белгече<br>Икътисадый анализ һәм прогнозлау бүлегенең баш белгече<br>Энергетика бүлегенең баш белгече<br>Шәһәр оешмалары белән үзара эшчәнлек бүлегенең баш белгече |

2.7. Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, физик затларның 294-ФЗ санлы Федераль законны бозган өчен җаваплылыгы.

Тикшерүләр үткәрүгә нигезсез тоткарлык ясый торган, тикшерүләр үткәрүдән качарга тырышкан һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне үтәүдә ачыкланган кимчелекләрне үтәү турында муниципаль торак контроле органы күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәгән юридик затлар, юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре, физик затлар яки аларның вәкилләре Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә җавап тота.

2.8. Тикшерү үткәргәндә муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затларының җаваплылыгы.

Муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затлары, тикшерү үткәргәндә тиешле функцияләрен, вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокуксыз эш иткән (эш итмәгән) очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

Муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларның хезмәт вазыйфаларын үтәүләрен контрольдә тота, вазыйфаи затларның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләре үткәрә һәм вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын бозуда гаепле вәкаләтле затларга карата мондый чаралар күрелгән көннән башлап ун көн эчендә муниципаль торак контроле органы бу хакта хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка кабул ителгән чаралар турында язмача рәвештә хәбәр җибәрергә тиеш.

# 3 бүлек. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга куела торган мәҗбүри таләпләр

## Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Эшчәнлек төре, күрсәткеч | Мәҗбүри таләпләрнең формулировкасы | Мәҗбүри таләпләрне билгеләүче норматив хокукый актлар |
|---|---|---|
| Күп фатирлы йортлар белән идарә итү; күп фатирлы йортларның гомуми мөлкәтен карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару; барлык төр коммуналь ресурсларны кую; гражданнарга торак бүлмәләрне наем килешүе буенча бирү | Торак биналарны файдалану буенча таләпләрне үтәү | Россия Федерациясе Торак кодексының 17 маддәсе |
| | Күп фатирлы йорт торак милекчеләренең гомуми җыелышының яисә торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзаларының гомуми җыелышы карарларын кабул иткәндә закон таләпләрен үтәү | Россия Федерациясе Торак кодексының 46 маддәсе |
| | Күп фатирлы йорт белән идарә итү килешүен, күп фатирлы йортларның гомуми мөлкәтен карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару килешүен законнар нигезендә төзү | Россия Федерациясе Торак кодексының 161, 162 маддәләре, РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.3 пункты 2.1.1, 2.1.5, 2.2.2. пунктчалары |
| | Күп фатирлы йорт милекчеләренең күп | Россия |

| | |
|---|---|
| фатирлы йорт бүлмәләренә, милекчелек формасына бәйсез рәвештә, күп фатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында торак законнары таләпләрен үтәүләре | Федерациясе Торак кодексының 161 маддәсе |
| Күп фатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәттән файдаланулары, шул гомуми мөлкәтне карап тотуга таләпләрне үтәүләре, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләрне үз вакытында башкару, әгәр барлык торак һәм (яки) торак булмаган бүлмәләр яисә аларның өлеше закон таләпләре нигезендә муниципаль мөлкәттә булса | Россия Федерациясе Торак кодексының 36, 39 маддәләре, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларын раслау турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары, РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 3 апрелендәге 290 нчы карары белән расланган Күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару кагыйдәләренең 6,7,8,9 пунктлары |
| Торак мөнәсәбәтләре һәм торак законнарын саклау өлкәсендәге кимчелекләрне бетерү турындагы таләпләрне үтәү | Россия Федерациясе Торак кодексының 20 маддәсе |
| Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү турында | «Энергия саклау һәм энергетика |

| | |
|---|---|
| муниципаль торак фондына карата законнарда билгеләнгән таләпләрне үтәү | нәтиҗәлелеген күтәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ санлы Федераль закон |
| Муниципаль торак фондыннан файдалану, муниципаль торак фонды торак биналарыннан файдалану кагыйдәләрен үтәү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак биналардан файдалану кагыйдәләрен билгеләү турында» 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 нче карары |
| Муниципаль торак фондының торак бүлмәләрен наемга алучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен үтәү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йортларда милекчеләргә һәм бүлмәләрдән файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 нче карары |
| Муниципаль торак фондын сезонлы эксплуатацияләүгә әзерләү | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник |

| | | |
|---|---|---|
| | | эксплуатациялэү кагыйдэлэре һэм нормаларының 2.6.10 пункты, 2.1.1, 2.6.4. пунктчалары |
| | Күп фатирлы йорттагы бүлмэлэрнең бер өлеше муниципаль милектэ урнашкан һэм шул ук вакытта муниципаль берэмлек өлешенең күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкэткэ хокукы 50 проценттан ким тэшкил иткэн очракта, күп фатирлы йорт белэн идарэ итү килешүе төзү максатында, учредительлэр составына муниципаль берэмлеклэр кергэн торак милекчелэр ширкэтлэре төзү, күп фатирлы йорттагы торак милекчелэре тарафыннан күп фатирлы йорт белэн идарэ итү эшчэнлеген гамэлгэ ашыручы юридик затны яки шэхси эшмэкэрне сайлау | Россия Федерациясе Торак кодексының 135 маддэсе |

4 бүлек. Юридик зат, шэхси эшмэкэр, физик зат тикшерү үткэргэндэ тапшырырга тиешле документлар

Юридик зат, шэхси эшмэкэр, физик зат тикшерү үткэрүнең максатлары һэм бурычларына ирешү өчен тапшырырга тиешле документлар исемлеге

| Тикшерү үткэрү өчен тапшырыла торган документ | Документның формасын билгелэүче норматив хокукый акт |
|---|---|
| Юридик затның, шэхси эшмэкэрнең хокук бирүче документлары, мэнфэгатьлэрен кайгыртуга тикшерү актын имзалау хокукына ия ышаныч язуы, паспорт | Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Аерым эшчэнлеклэрне лицензиялэү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш һэм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Торак фондын техник эксплуатациялэү кагыйдэлэре һэм нормаларын раслау |
| Гамэлгэ ашыра торган эшчэнлек төрлэренэ лицензия (алар лицензиялэнгэн очракта) | |
| Муниципаль мөлкэттэге торакка килешү наемы, ордерлар | |
| Күп фатирлы йортларда торак милекчелэренең гомуми җыелышы беркетмэсе; тавыш бирү реестры, тавыш бирү өчен бюллетеньнэр, белдерү язуы реестры, ышаныч язулары | |
| Күп фатирлы йорт белэн идарэ итү килешүе; күп фатирлы йортны карап тоту һэм гомуми мөлкэтне | |

| | |
|---|---|
| ремонтлау буенча хезмәт күрсәтү һәм (яки) эшләр башкаруга килешү; барлык төр коммуналь ресурсларны бирүгә килешү | турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәт күрсәтүләр һәм эшләрнең минималь исемлеге, аларны күрсәтү һәм үтәү тәртибе турында» 2013 елның 3 апрелендәге 290 нчы карары |
| Күп фатирлы йортка капиталь ремонт үткәрү турында күп фатирлы йортның торак милекчеләренең гомуми җыелышы карарлары, планнары, капиталь ремонтка титул исемлекләре, капиталь ремонтка проект-смета документлары, подряд килешүләре | |
| Энергия һәм су ресурсларын исәпләү, җайга салу һәм контрольдә тоту исәпләү приборларының, исәпләү приборларының инструкцияләре, паспортлары, эксплуатацияләүгә кертү актлары, күрсәткечләрне алу журналлары, файдаланылган ресурсларның саны турында ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән төзелгән чагыштырып тикшерү актлары булу турында мәгълүмат | |
| Күп фатирлы йортның торак милекчеләре алдында еллык хисап; Агымдагы елга торак фондының гомуми мөлкәтен агымдагы ремонтлау (эшләр исемлеге) планы; Киләсе елга торак фондының гомуми мөлкәтен агымдагы ремонтлау (эшләр исемлеге) планы һәм аның үтәлеше | |
| Йорт эчендәге инженерлык системалары һәм квартал эчендәге җиһазларның техник торышы билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаучы документлар; Күп фатирлы йортның гомуми мөлкәтенә караган конструкция һәм инженерлык җиһазларының техник торышын планлы карау үткәрү турындагы документлар; Күп фатирлы йортның гомуми мөлкәтен тиешенчә карап тоту буенча эшләр башкаруга документлар; Башкарылган эшләрнең актлары | |
| Торак фондын алдагы елга сезонлы эксплуатацияләүгә әзерләү буенча чаралар планы һәм аның үтәлеше; Күп фатирлы йортларның кышкы чорда эксплуатацияләүгә әзерлеге паспортлары | |
| Халыктан заявкалар кабул итү, аларның үтәлеше, контрольне гамәлгә ашыру, шул исәптән тәүлеклек авария хезмәте күрсәтүне оештыру буенча документлар | |
| Контейнер мәйданчыкларын җыештыру графигы | |

## 5 бүлек. Административ процедураларның (эшләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр

Муниципаль торак контроле юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне һәм физик затларны планлы (документар һәм күчмә) һәм планнан тыш (документар һәм күчмә) тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләр башкаруның административ процедуралары (эшләре) блок-схемасы әлеге Административ регламентның 6 нчы кушымтасында бирелгән.

5.1. Планлы тикшерү үткәрүнең административ процедуралары.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру максатында юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне һәм физик затларны планлы тикшерү үткәрү түбәндәге административ процедураларны күздә тота:

- юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне һәм физик затларны планлы документар тикшерү үткәрү;
- юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне һәм физик затларны планлы күчмә тикшерү үткәрү;

5.1.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм физик затны планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедурасы

5.1.1.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм физик затны планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен тиешле юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм физик затны еллык планга кертү нигез булып тора. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм физик затны планлы тикшерүне еллык Планга кертү әлеге Административ регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән нигездә гамәлгә ашырыла.

«Юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм физик затны планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедурасы түбәндәге эш тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

- планлы документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле затларны билгеләү турында карар кабул итү;
- планлы документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкны рәсмиләштерү;
- юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга документар тикшерү үткәрү турында хәбәр итү;
- планлы документар тикшерү үткәрү;
- планлы документар тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.1.1.2. Муниципаль торак контроле органы җитәкчесе план нигезендә:

- җаваплы башкаручыларны билгели, монда карар кабул итү критерие булып вазыйфаи затның (алга таба – җаваплы башкаручы) юридик затны, шәхси эшмәкәрне һәм физик затны тикшерү үткәрү өчен әлеге Административ регламентның 2.6 пункты нигезендә тикшерүләр үткәрүгә вәкаләте булу тора;
- кирәк булган очракта, тикшерү үткәрелә торган юридик зат, шәхси

эшмәкәр, физик зат белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилирланган затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә һәм физик затка хәбәр итү өчен кирәкле вакытны исәпкә алмыйча (хәбәр итүгә исәпләнгән вакыт хәбәр итү алымына бәйле), тикшерү үткәрә башлауга кадәр 5 эш көненнән дә соңрак түгел, яисә турыдан-туры еллык План төзегәннән соң.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.1.1.3. Җаваплы башкаручы:

- РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче санлы Приказы белән расланган 1 нче кушымта нигезендә юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны тикшерү турында боерык проекты, юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат объектында (объектларында) күзәтчелек буенча чаралар үткәрү буенча җаваплы башкаручыларга план-йөкләмә әзерли;

- боерык проектын муниципаль контроль органы җитәкчесенә имзаларга җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә һәм физик затка хәбәр итү өчен кирәкле вакытны исәпкә алмыйча (хәбәр итүгә исәпләнгән вакыт хәбәр итү алымына бәйле), тикшерү үткәрә башлауга кадәр 30 эш көненнән дә соңрак түгел.

Эш итүнең нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү турында муниципаль контроль органы җитәкчесе имзалаган боерык.

5.1.1.4. Җаваплы башкаручы юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны тикшерү үткәрү турында муниципаль контроль органы җитәкчесе боерыгының күчермәсен, белдерү кәгазе белән почта аша заказлы хат җибәрү юлы белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ аша юридик затка, шәхси эшмәкәргә һәм физик затка электрон почта адресына җибәрә, әгәр андый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында яисә элек юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан, яки башка уңайлы юл белән муниципаль контроль органына бирелгән булса.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм физик зат адресына тикшерү үткәрү турында хәбәр җибәрү эш кәгазьләрен алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә язып куела.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрә башлауга кадәр өч эш көненнән дә соң түгел.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм физик зат адресына тикшерү үткәрү турында җибәрелгән боерыкның күчермәсе.

Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзаларын планлы күчмә тикшерү үткәрү очрагында, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга салучы оешмага аның вәкиленең планлы күчмә тикшерү үткәргәндә катнашуын яки анда булуын тәэмин итү максатында, плансыз күчмә тикшерү үткәрү турында хәбәр бирә.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм физик зат муниципаль торак контроле органына тикшерү үткәрү турындагы боерык күчермәсендә күрсәтелгән, мөһер сугылган (булганда) һәм шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, җитәкченең, юридик затның, физик затның башка вазыйфаи затының имзасы куелган документларны күчермә рәвешендә 10 эш көне эчендә җибәрә.

Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, документлар күчермәләренең нотариаль раслануын таләп итүгә юл куелмый.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр запроста күрсәтелгән документларны электрон документлар рәвешендә җибәрергә хокуклы. Аларга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган булырга тиеш.

5.1.1.5. Документар тикшерү үткәрү процессында җаваплы башкаручылар тарафыннан иң беренче чиратта, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның билгеләнгән тәртиптә муниципаль торак контроле органы карамагына тапшырылган документлары, элекке тикшерүләрнең актлары, административ хокук бозулар турында һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка карата элек гамәлгә ашырылган тикшерүләрнең нәтиҗәләре турындагы башка документлар карала.

Документар тикшерү үткәргәндә, муниципаль торак контроле органының юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, физик заттан документар тикшерү предметына карамаган мәгълүмат һәм документларны, шулай ук башка дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган мәгълүмат һәм документларны таләп итәргә хокукы юк.

5.1.1.6. Җаваплы башкаручы, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның документларын карау нәтиҗәләре нигезендә, юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат адресына хат (дәлилле запрос) җибәрү (җибәрмәү) турында карар кабул итә.

Мәгълүматларның дөреслеге карар кабул итүнең критерие булып санала. Әгәр документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырса яисә әлеге мәгълүматлар мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү мөмкинлеге бирмәсә, хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланса, муниципаль торак контроле органына бирелгән һәм анда булган мәгълүматлар тәңгәл килмәсә, ул очракта җаваплы башкаручы:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат адресына мәгълүматларны бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны һәм 10 эш көне эчендә язмача рәвештә тиешле аңлатмаларны яисә карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру турында дәлилләнгән запрос белән хат әзерли;

- тикшерү үткәрү турында җитәкченең мөһер сугылган боерыгы күчермәсе белән булган дәлилләнгән запросны юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат адресына белдерү кәгазе белән заказлы хат итеп почта аша яисә башка уңайлы юл белән (факсимиль элемтәсе, электрон почта, иясенә тапшыру турында билге белән) җибәрә.

Хат, дәлилләнгән запрос җибәрү эш кәгазьләрен алып бару

кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә язып куела.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрә башлауга кадәр 5 эш көне эчендә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм физик зат адресына карау өчен кирәкле булган башка документларны тапшыру турында җибәрелгән хат (дәлилләнгән запрос).

5.1.1.7. Әгәр бирелгән аңлатмаларны һәм (яки) элек тапшырылган документларның дөреслеген раслаучы документларны караганнан соң, яисә аңлатмалар булмаганда мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре күренсә, муниципаль торак контроле органы бу очракта күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

Күчмә тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр һәм физик заттан документар тикшерү барышында тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итү тыела.

Күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарны җитәкче аны җаваплы башкаручы тарафыннан үткәрү кирәклеген дәлилләүне истә тотып кабул итә. Күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарны кабул итү критерие булып карау барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат тарафыннан билгеләнгән аңлатмалар һәм (яки) документлар, күчмә тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт иткән мәҗбүри таләпләрнең бозылу билгеләре булу тора.

Күчмә тикшерү (аны үткәрү турында карар кабул ителгәндә) әлеге Административ регламентның 5.1.2 пунктында китерелгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үтәү срогы: аңлатмалар алган вакыттан башлап 15 эш көне эчендә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан каралган, юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат тарафыннан тапшырылган аңлатмалар һәм (яки) документлар; кирәк булганда күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проекты.

5.1.1.8. Җаваплы башкаручы юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик затларның планлы документар тикшерү нәтиҗәләре буенча 3 нче кушымта нигезендә (РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче санлы Приказы белән расланган тикшерү актының типовой формасы) ике данәдә акт төзи.

Мәҗбүри таләпләргә контроль буенча чаралар үткәрү нәтиҗәсендә кимчелекләр ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнарны саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән (ачыкланган кимчелекләр нәтиҗәсендә килгән зыянны кире кайтару) түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- тикшерү актында кимчелекләр ачыкланган барлык очракны язып куя;

- юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка срокларын күрсәтеп кимчелекләрне бетерү турында һәм (яки) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча

кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар турында үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмә бирә, ул тикшерү актына кушымта булып санала (һәр кимчелек буенча аерым күрсәтмә), һәм әлеге күрсәтмәләрнең әлеге Административ регламентта каралган тәртиптә билгеләнгән срокларда үтәлүен контрольдә тота;

- торак законнары таләпләрен бозулар ачыкланганда, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары буенча административ һәм башка җаваплылык каралган, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә чара күрү өчен тикшерү актын дәүләт торак күзәтчелеге органына җибәрә.

Әгәр тикшерү үткәргәндә юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур бүлекчәсенең, шәхси эшмәкәрнең, аларга караган биналар, төзелешләр, корылмалар, бүлмәләр, җиһазлар, шундыйрак объектлар, транспорт чаралары, алар тарафыннан җитештерелә һәм сатыла торган товарлар (башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу яки андый зарар китерү очраклары булганда, муниципаль торак контроле органы зыян китерүне булдырмау яки аны булдыруны туктату өчен РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексында билгеләнгән тәртиптә юридик затның, аның филиалының, вәкиллегенең, структур бүлекчәсенең, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеген вакытлыча тыюга кадәр, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерү куркынычы булган продукцияне әйләнештән алу һәм гражданнар, шулай ук юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр игътибарына теләсә нинди уңайлы алымнар аша зыян килү куркынычы һәм аны булдырмый калу юллары турында җиткерү буенча кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

Әгәр контроль буенча чаралар барышында хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең контроль буенча чаралар үткәрү объекты булуы билгеле булса, закон таләпләрен бозып гамәлгә ашырылса, ачыклау, булдырмый калу һәм юл куймау мәсьәләләре муниципаль контроль органы компетенциясенә карамый. Муниципаль торак контроле органы андый кимчелекләр турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органнарына

җибәрергә тиеш.

Җаваплы башкаручы тикшерү актының (кушымталары белән бергә) бер нөсхәсен делога тегеп куя, икенчесен (кушымталары белән бергә) тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турындагы расписка белән җитәкчегә, юридик затның башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик затка яки аның вәкиленә тапшыра.

Җитәкче, юридик затның башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, физик зат яки аның вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турында распискадан баш тарткан очракта, акт белдерү кәгазе белән почта аша заказлы хат белән җибәрелә, тапшырылу турындагы хәбәр делода саклана торган акт нөсхәсен теркәп куела. Тикшерелә торган затның, муниципаль контроль кысаларында, үзара эшләүне электрон рәвештә гамәлгә ашыруга рөхсәте булганда, әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган тикшерү акты җитәкчегә, юридик затның башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, физик зат яки аның вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта, әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган, тикшерелә торган затка күрсәтелгән документны алуын раслауны тәэмин итү юлы белән электрон рәвештә җибәрелгән актны тикшерелә торган зат алган булып санала.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң;

- тикшерү актын заказлы хат белән җибәрү: контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аларның берсе юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка тапшырыла (җибәрелә), икенчесе делога тегеп куела.

5.1.1.9. Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга салучы оешмага ачыкланган кимчелекләр турында тикшерү тәгәлләнгән көннән башлап 5 эш көне эчендә хәбәр итә.

5.1.2. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы;

5.1.2.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен тиешле юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны муниципаль торак контроле органының еллык Планына кертү, шулай ук планлы документар тикшерү (әлеге Административ регламентның 5.1.1.7 пункты) нәтиҗәсе булып саналган планлы күчмә тикшерү үткәрү турында боерык нигез булып тора, әгәр планлы документар тикшерү мөмкинлеге булмаса:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик затның муниципаль торак контроле органы боерыгы документларындагы мәгълүматларның

тулылыгына һәм дөреслегенә ышану;

- юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат эшчәнлегенең, контроль буенча тиешле чаралар үткәрмичә, мәҗбүри таләпләргә яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү;

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планлы тикшерүне еллык Планга кертү әлеге Административ регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

«Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы әлеге Административ регламентның 5.1.1.1 пунктында күрсәтелгән эш тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.1.2.2. Җаваплы башкаручыны, экспертларны билгеләү, юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планлы тикшерү үткәрү турындагы боерыкны әзерләү, юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планлы тикшерү үткәрү турында хәбәр итү әлеге Административ регламентның 5.1.1.2 - 5.1.1.4 пунктларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.1.2.3. Җаваплы башкаручы, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат объектына килгәч, тикшерүне түбәндәгечә башлыйлар:

- хезмәткәр таныклыгын күрсәтәләр;

- җитәкчене яки юридик затның башка вазыйфаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, физик затны яки аның вәкилен муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыгы белән мәҗбүри рәвештә таныштыралар;

- җитәкчене яки юридик затның башка вазыйфаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен, физик затны яки аның вәкилен күчмә тикшерү үткәрүчеләрнең вәкаләтләре, шулай ук күчмә тикшерү үткәрүнең максаты, бурычлары, нигезлелеге, контроль буенча чара төрләре һәм күләмнәре, күчмә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертлар составы, эксперт оешмаларның вәкилләре, аны үткәрүнең сроклары һәм шартлары белән мәҗбүри рәвештә таныштыралар.

- Җаваплы башкаручы контроль буенча түбәндәге чараларны үткәрә:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат эшчәнлегенең әлеге Административ регламентның 3 бүлегендә китерелгән мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяли;

- планлы күчмә тикшерү актын тутыра.

Планлы күчмә тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат тарафыннан мәҗбүри таләпләр үтәлмәве ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

- кимчелекләр ачыкланган барлык очракны тикшерү актында язып куя;

- юридик затка, шәхси эшмәкәргә, физик затка срокларын күрсәтеп кимчелекләрне бетерү турында һәм (яки) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм

мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга, дәүләт куркынычсызлыгына, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яки муниципаль мөлкәткә зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар турында күрсәтмә бирә. Күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып санала (һәр кимчелек буенча аерым күрсәтмә чыгарыла);

- мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән юридик зат хезмәткәрләренең, шәхси эшмәкәрнең, шулай ук физик затларның аңлатуларын соратып ала.

Үтәү срогы: юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планлы тикшерү үткәрүнең гомуми срогы 20 эш көненнән артык түгел.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләү максатында, муниципаль торак контроле буенча үткәрелгән чаралар.

5.1.2.4. Тикшерү актын төзү әлеге Административ регламентның 5.1.1.8 пунктында күрсәтелгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җаваплы башкаручы тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән тикшерү, муниципаль торак контроле органының исеме, тикшерү үткәрә башлау һәм тәгәлләү даталары, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезлелеге, бурычлары, максатлары һәм тикшерү предметы, ачыкланган кимчелекләр һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы мәгълүматлар булган язуны, шулай ук тикшерү үткәрүче вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфаларын, аның яки аларның имзаларын язып куюны гамәлгә ашыра.

5.1.2.5. Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыклану очрагында, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга салучы оешмага ачыкланган кимчелекләр турында тикшерү тәгәлләнгән көннән башлап 5 эш көнендә хәбәр җибәрә.

5.1.2.6. Әгәр шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты, физик зат, аның вәкаләтле вәкиле булмау сәбәпле, планлы күчмә тикшерү үткәрү мөмкин булмаса, яисә тикшерү үткәрүгә мөмкинлек булмауга китергән юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең фактта эшчәнлек алып бармавы, яисә шәхси эшмәкәрнең башка эш итүе (эш итмәве) сәбәпле, муниципаль торак контроле органының вазыйфаи заты, әлеге тикшерүне үткәрү мөмкин булмау турында, аның сәбәпләрен дә күрсәтеп, акт төзи. Бу очракта муниципаль торак контроле органы, тикшерүне үткәрү мөмкин булмау турындагы акт төзегән көннән башлап өч ай эчендә андый юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затларга карата планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерүләрне тикшерүләр үткәрүнең еллык Планына кертмичә, юридик

затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затларга алдан хәбәр бирмичә карар кабул итәргә хокуклы.

5.2. Планнан тыш тикшерү үткәрүнең Административ процедуралары.

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру максатында юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, физик затларны планнан тыш тикшерүләр үткәрү түбәндәге административ процедураларны күздә тота:

- юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, физик затларны планнан тыш документар тикшерүне үткәрү;

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү.

5.2.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш документар тикшерүне үткәрү» административ процедурасы.

5.2.1.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш документар тикшерүне үткәрү» административ процедурасын башлау өчен әлеге Административ регламентның 2.5.3 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

«Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш документар тикшерүне үткәрү» Административ процедурасы түбәндәге эш тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

- планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле затларны билгеләү турында карар кабул итү;

- планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;

- планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

- планнан тыш документар тикшерүнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.2.1.2. Муниципаль торак контроле органы җитәкчесе, әлеге Административ регламентның 2.5.3 пунктчасында күрсәтелгәнчә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез барлыкка килгәндә, планнан тыш документар тикшерүне оештыру һәм үткәрү турында йөкләмә бирә.

Муниципаль торак контроле органы җитәкчесе:

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгели;

- кирәк булган очракта, тикшерү үткәрелә торган юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилирланган затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү срогы: планлы тикшерү үткәрү өчен нигез барлыкка килгәннән башлап 10 эш көнендә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгеләү.

5.2.1.3. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны тикшерү үткәрү турындагы боерыкны, әлеге Административ регламентның 5.1.1.3 пункты нигезендә, юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгеләгән

көндә әзерләү.

5.2.1.4. Юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның документларындагы мәгълүматларны бәяләү, юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат адресына хат (нигезле запрос) әзерләү, әлеге Административ регламентның 5.1.1.5 - 5.1.1.7 пунктлары нигезендә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, физик затның документларындагы кимчелекләргә аңлатмаларын карау буенча җаваплы башкаручының эшләре.

5.2.1.5. Тикшерү акты төзү, юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны тикшерү акты (аларны тутыру кирәк булганда кушымталары белән) белән таныштыру әлеге Административ регламентның 5.1.1.8 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Элек ачыкланган закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәүне тикшергәндә Административ хокук бозулар турында эш кузгату өчен муниципаль торак контроле органының законлы күрсәтмәсен срогында үтәмәү, шулай ук РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының 19.5, 19.6 маддәләрендә каралган административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрмәү нигез булып тора.

Кабат ачыкланган кимчелекләр, шулай ук системалы характерга ия кимчелек фактлары мәҗбүри тәртиптә язып куела.

5.2.2. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы.

5.2.2.1. «Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны плансыз күчмә тикшерү үткәрү» Административ процедурасын башлауга әлеге Административ регламентның 2.5.3 пунктында күрсәтелгән очраклар, шулай ук документар тикшерү вакытында мөмкин булмау нигез булып тора:

- муниципаль торак контроле органы боерыгында булган юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат документларындагы мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслегенә ышану;

- муниципаль торак контроле буенча тиешле чаралар үткәрмичә, юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә яки муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү.

«Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы әлеге Административ регламентның 5.1.1.1 пунктында күрсәтелгән эш тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2.2. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгеләү, эксперт оешмалар вәкилләрен җәлеп итү әлеге Административ регламентның 5.2.1.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2.3. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында приказ (боерык) әзерләү әлеге Административ регламентның 5.1.1.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2.4. Әлеге Административ регламентның 2.5.3 пункты

3 пунктчасының «а», «б» пунктчаларында саналган нигезләр планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрүгә нигез булган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәгеләрне башкара:

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган урын буенча прокуратура органына гариза әзерли һәм аңа муниципаль торак контроле органы җитәкчесеннән имза куйдыра;

- юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында гаризаны юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган урын буенча прокуратура органына үз кулы белән бирә, белдерү кәгазе белән почта аша яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә җибәрә.

Гаризага планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыкның күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булып торучы мәгълүматлар булган документлар теркәлә.

Үтәү срогы: юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боеру приказына кул куелган көндә.

Эш итүнең нәтиҗәсе: юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында прокуратура органына җибәрелгән гариза.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, дәүләт куркынычсызлыгына зарар килү, шундый кимчелекләрне эшләү моментына мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылу ачыклану нигез булып торса, кичектергесез чаралар күрергә кирәк булу сәбәпле, муниципаль торак контроле органы, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында прокуратура органына гариза, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы боерыкның күчермәсен һәм аны үткәрүгә нигез булып торучы мәгълүматлар булган документларны 24 сәгать эчендә җибәреп, тиз арада планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә керешергә хокуклы. Бу очракта, прокурор яки аның урынбасары, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килешенү турында тиешле документлар кергән көндә хәл итә.

5.2.2.5. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында (әлеге Административ регламентның 2.5.3 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерү нигез булып торудан тыш) теләсә нинди уңайлы юл белән ул башланганчы 24 сәгатьтән

ким булмаган вакытта хәбәр итә.

Әгәр юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар килгән, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан, дәүләт куркынычсызлыгына зарар килгән очракта, юридик затка, шәхси эшмәкәрләргә планнан тыш күчмә тикшерү башлану турында алдан хәбәр итү соралмый.

Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзаларын планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү очрагында, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга салучы оешмага аның вәкиленең планнан тыш күчмә тикшерү үткәргәндә катнашуын яки анда булуын тәэмин итү максатында, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында хәбәр бирә.

5.2.2.6. Планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү әлеге Административ регламентның 5.1.2.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2.2.7. Тикшерү актын төзү әлеге Административ регламентның 5.1.1.8 һәм 5.1.2.4 пунктлары нигезендә башкарыла.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органы белән килешенү буенча гамәлгә ашырылган булса, тикшерү акты күчермәсе прокуратура органына тикшерү акты төзелгән көннән башлап биш эш көне эчендә җибәрелә.

Элек ачыкланган закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең үтәлешен тикшергәндә, административ хокук бозулар турында эш кузгату максатында, материалларны дәүләт күзәтчелеге органнарына тапшыру өчен муниципаль контроль органының законлы күрсәтмәсен срогында үтәмәү, шулай ук РФ Административ хокук бозулар турында кодексының 19.5, 19.6 маддәләрендә каралган административ хокук бозулар эшләүгә китерүче сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрмәү нигез булып тора.

Кабат ачыкланган кимчелекләр, шулай ук системалы характерга ия кимчелек фактлары мәҗбүри рәвештә язып куела.

5.2.2.8. Үз-үзен җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы үз-үзен җайга салучы оешмага ачыкланган кимчелекләр турында планнан тыш күчмә тикшерү тәгәлләнгән көннән башлап биш эш көне эчендә хәбәр итә.

5.3. Тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү тәртибен билгеләүче 294-ФЗ санлы Федераль закон нигезләмәләре түбәндәге очракларда кулланылмый:

1) контроль буенча чаралар үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнарның үзара

эшләве таләп ителми, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга һәм күрсәтелгән затларга дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнарның таләпләрен үтәү һәм мәгълүмат бирү буенча вазыйфалар йөкләнми;

2) производствода аварияләр, бәхетсезлек очраклары килеп чыгу, кешеләрнең, хайваннарның һәм үсемлекләрнең йогышлы һәм массакүләм йогышлы булмаган авырулары (агуланулары, зарарланулары), әйләнә-тирә мохиткә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә зыян китерү сәбәпләрен тикшергәндә.

## 6 бүлек. Муниципаль функцияләрне үтәү тәртибе һәм контроль формалары

6.1. Муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларның үз хезмәт вазыйфаларын башкаруларына контрольне гамәлгә ашыра, тикшерүләр үткәрү барышында вазыйфаи затларның үз вәкаләтләрен тиешенчә башкармау очракларының исәбен алып бара, тиешле тикшерүләр үткәрә һәм вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

6.2. Әлеге Административ регламентны үтәүгә контроль муниципаль торак контроле органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.3. Әлеге Административ регламент нигезендә муниципаль торак контролен үтәү буенча эш итүнең срокларын, эзлеклелеген саклауга, муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының карарлар кабул итүенә агымдагы контрольне муниципаль торак контроле органының вәкаләтле хезмәткәрләре гамәлгә ашыра.

6.4. Муниципаль торак контроле органының муниципаль функцияләрне үтәүгә агымдагы контрольне, әлеге контрольне гамәлгә ашыру тәртибен һәм аның периодиклылыгын тормышка ашыруга вәкаләтле хезмәткәрләр исемлеге муниципаль торак контроле органы актлары белән билгеләнә. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыруга муниципаль торак контроле органы хезмәткәрләренең вәкаләтләре муниципаль торак контроле органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрендә билгеләнә.

6.5. Муниципаль торак контроле органының муниципаль функцияләрне үтәвенең тулылыгына һәм сыйфатына контроль планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне, тикшерелә торган затларның хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) кызыксынган затларның мөрәҗәгатьләрен карау, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүгә контрольне дә үз эченә ала.

Тикшерүләр муниципаль торак контроле органы җитәкчесе боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерүләр нәтиҗәләре акт рәвешендә рәсмиләштерелә, анда муниципаль функцияләр үтәгәндә җитешсезлекләр булмау яисә ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча

тәкъдимнәр язып куела.

6.6. Муниципаль функция үтәүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы тикшерүләр муниципаль торак контроле органының агымдагы ел тикшерүләренең еллык планына туры китереп үткәрелә. Планлы тикшерүләр муниципаль функцияләр үтәү компетенциясенә кергән муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең күрсәтелгән планына кертелә.

6.7. Муниципаль функцияләр үтәүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерүләр муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияләр үтәгәндә кабул ителгән яки гамәлгә ашырылган карарларына яки эш итүләренә (эш итмәүләренә) гражданнарның шикаятьләре (дәгъвалары) нигезендә үткәрелә.

6.8. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияләр үтәгәндә җибәргән кимчелекләре ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла һәм ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрелә.

6.9. Муниципаль торак контроле органының муниципаль функцияләр үтәүгә җаваплы вазыйфаи затлары функцияләр үтәгәндә кабул ителгән яки гамәлгә ашырылган карарларына яки эш итүләренә (эш итмәүләренә) җаваплы санала.

Муниципаль торак контроле органы вәкаләтле затларының җаваплылыгы аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китерелгән вазыйфаи инструкцияләр белән ныгытыла.

6.10. Җәмәгать торак контроле торак мөнәсәбәтләре өлкәсендәге законнарны үтәү һәм закон бозуларны кисәтү буенча һәркемнең хокукын тормышка ашыру максатында гамәлгә ашырыла. Җәмәгать торак контроле җәмәгать берләшмәләре һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциясез оешмалар, аларның уставлары нигезендә, күп фатирлы йорт советлары, башка кызыксынган затлар тарафыннан законлы нигездә гамәлгә ашырыла.

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган җәмәгать торак контроле нәтиҗәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиеш.

## 7. бүлек. Муниципаль функцияләр үтәүче органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

7.1. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, физик зат яки аның вәкиле, башка кызыксынган затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затлары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерү вакытында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның хокуклары бозылуга юл куелса, муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затларының муниципаль функцияләрен үтәү барышында эш итүләренә (эш итмәүләренә)

судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү хокукына ия.

7.2. Муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затларының судка кадәр (судтан тыш) эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирү предметы булып муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияләрне үтәү барышында кабул иткән яки гамәлгә ашырган карарлары яки эш итүләре (эш итмәүләре) тора.

7.3. Муниципаль торак контроле органына яки вазыйфаи затка кергән шикаять аларның компетенциясе чикләрендә мәҗбүри рәвештә карап тикшерелергә тиеш. Шикаятьне судка кадәр (судтан тыш) карап тикшерүне яки туктатып торуны кире кагу өчен сәбәпләр булырга тиеш түгел.

7.4. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми:

- әгәр язмача шикаятьтә шикаять җибәрүченең фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса (әгәр күрсәтелгән шикаятьтә хокук бозу юлы белән әзерләнә, башкарыла яки башкарылган эшләр турында, шулай ук аны әзерләгән, башкара торган яки башкарган зат турында мәгълүматлар булса, шикаять үз компетенциясе чикләрендә дәүләт органына юлланырга тиеш);

- әгәр шикаятьтә цензуралы булмаган яки кимсетүле сүзләр, муниципаль торак контроле органының вазыйфаи заты тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә, шулай ук аның гаилә әгъзаларына куркыныч янау булса (муниципаль торак контроле органының вазыйфаи заты шикаять итүчегә хокукыннан явыз ниятта файдалану ярамаганлыгын хәбәр итәргә хокуклы);

- әгәр язмача шикаять тексты укырлык булмаса (күрсәтелгән шикаять шулай ук карап тикшерү өчен компетенция чикләрендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш түгел), бу хакта шикаять теркәлгәннән башлап 7 көн эчендә шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ирелә, әгәр аның фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), почта адресы укырлык дәрәҗәдә булса;

- әгәр гариза бирүченең шикаятендә аның элек җибәрелгән шикаятьләренә берничә тапкыр нигезле җаваплар бирелгәннән соң да шикаятьнең составында яңа хәбәрләр яки хәлләр китерелмәгән сорау булса (әлеге шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки бер үк вазыйфаи затка юлланган булса), (шикаять җибәрүчегә язышуны туктату карары турында хәбәр ителә);

- әгәр шикаятьтә куелган нигезле сорау буенча җавап дәүләт яки башка федераль закон белән саклануучы сер булган мәгълүматларны таратмыйча бирелә алмаса (шикаять җибәрүчегә анда куелган сорауга әлеге мәгълүматларны тарату ярамау сәбәпле, нигезле җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә).

7.5. Муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып шикаять бирүчедән (шикаять

бирүченең вәкаләтле вәкиленнән) шәхсән почта аша юллау, Интернет челтәрендәге мәгълүмати-телекоммуникацияләрне кулланып электрон документ рәвешендә, шулай ук муниципаль торак контроле органының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша шикаятьләр керү тора.

7.6. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар шикаятьләрне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүмат һәм документларны алырга хокуклы. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар, мондый төрдәге мәгълүмат һәм документларны алу өчен, муниципаль торак контроле органына тиешле запросларын язмача рәвештә җибәрергә тиешләр. Җитәкче, җаваплы башкаручылар соралган мәгълүмат һәм документларны запрос теркәлгән көннән башлап 30 календарь көн эчендә бирергә тиешләр.

7.7. Муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затының эш итүенә (эш итмәвенә) шикаять муниципаль торак контроле органы җитәкчесенә җибәрелергә мөмкин. Муниципаль торак контроле органының эш итүенә (эш итмәвенә), карарына булган шикаять муниципаль берәмлекнең Башкарма комитетына җибәрелергә мөмкин.

7.8. Муниципаль торак контроле органына яки муниципаль торак контроле органының вазыйфаи затына аларның компетенцияләре чикләрендә кергән шикаять, ул теркәлгән көннән башлап 30 календарь көн эчендә карап тикшерелә.

Җирле үзидарә органы яки вазыйфаи зат шикаятьләрне карап тикшерә торган җирле үзидарә органы яки вазыйфаи затның билгеләнгән тәртиптә җибәрелгән запросына 30 календарь көн эчендә шикаятьне карап тикшерү өчен кирәкле документлар һәм материалларны бирергә тиеш, дәүләт яки башка федераль закон белән саклanучы сер булган һәм аларны аерым бирү тәртибе каралган мәгълүматлардан кала.

Искәрмә очракларда, шулай ук әлеге пунктта күрсәтелгән запросны җибәргән очракта, шуңа вәкаләтле булган зат шикаять карауны 30 календарь көннән артмаган срокка озайтырга хокуклы, срок озайтылу турындагы хәбәрне шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә җиткереп.

7.9. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр санала:

1) муниципаль функцияләрне үтәү барышында эш итүгә (эш итмәүгә) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларга карата судка кадәр (судтан тыш) шикаятьләрне канәгатьләндерү, ягъни:

- фактларны тикшерү барышында җаваплы башкаручының (җаваплы башкаручыларның) хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәүләре ачыкланган очракта, аларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чара күрү;

- хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозуда гаепле җаваплы башкаручыларга карата күрелгән чаралар турында шундый чаралар күрелгән көннән башлап 10 көн эчендә язмача хәбәр итү;

2) муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда эш итү (эш итмәү)

һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларны судка кадәр (судтан соң) юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга, физик затка, әлеге карарның дәлилләнгән нигезле булуын язмача хәбәр итү юлы белән, шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру. Муниципаль торак контроле органына яки вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән шикаятькә җавап шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә.

7.10. Муниципаль торак контроле органы шикаятьне карап тикшерү өчен шикаять итүчедән муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының нигезсез эш итүен раслаучы беренчел документларны электрон рәвештә соратып алырга хокуклы.

Соратып алынган материаллар мөрәҗәгать итүче тарафыннан запрос кергәннән башлап 30 календарь көн эчендә бирелергә тиеш.

7.11. Муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының эш итүләре (эш итмәүләре) нәтиҗәсендә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга китерелгән зыян Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә, урынсыз дип табылса, Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль бюджет акчалары хисабына кире кайтарылырга тиеш, килми калган файданы (алынмаган табышны) да кертеп.

7.12. Шикаятьне карау нәтиҗәләре федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә судта шикаять ителергә мөмкин.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Административ регламентка
1 нче кушымта

____________________________________________________________
жирле үзидарә органының яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән

____________________________________________________________
муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органның исеме

Муниципаль торак контроле органының
тикшерүләр үткәрү турында
боерыгы

____________________________________________
(планлы/планнан тыш, документар/күчмә)
юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат
«___» _____________ ______ ел. № _____

1. Тикшерү үткәрергә ________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

2. Урнашкан урыны: __________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(юридик затның (филиал, вәкиллек, аерымланган структур бүлекчәләрнең), шәхси эшмәкәр, физик затның эшчәнлекләрен факттагы гамәлгә ашыру урыны һәм (яки) алар файдаланган производство объектының урыны)

3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле зат (лар) итеп билгеләргә: ________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы)

4. Тикшерү үткәрүгә экспертлар, эксперт оешмалар вәкилләре сыйфатында түбәндәге затларны җәлеп итәргә:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы һәм (яки) аккредитациясе турында таныклык реквизитлары һәм аккредитация турында таныклык биргән орган күрсәтелгән эксперт оешмасының исеме)

5. Әлеге тикшерү түбәндәге кысаларда үткәрелә
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төренең (төрләренең) исеме, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы функциянең (функцияләрнең) реестр (реестрлар) саны (саннары)

6. Әлеге тикшерүнең максатын билгеләргә:

___

___

___

Үткәрелә торган тикшерүнең максатларын билгеләгәндә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а) планлы тикшерү үткәргән очракта:

- планлы тикшерүләр үткәрүнең расланган еллык планына сылтама;

- тикшерү кәгазе реквизитлары (контроль сораулар исемлеге), әгәр планлы тикшерү үткәргәндә тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) кулланылырга тиеш булса;

б) планнан тыш тикшерүләр үткәргән очракта:

- тикшерелә торган затка ачыкланган житешсезлеген бетерү турында элек бирелгән, үтәлү срогы чыккан күрсәтмәнең реквизитлары;

- юридик заттан яки шәхси эшмәкәрдән аерым эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга яки башка юридик әһәмиятле эшләр башкаруга хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирүгә алынган гариза реквизитлары, әгәр юридик затны, шәхси эшмәкәрне тиешле планнан тыш тикшерү үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия), рөхсәт бирү (килешенү) кагыйдәләрендә каралган булса;

- дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарына, муниципаль контроль органнарына гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән кергән мөрәҗәгать һәм гаризаларның реквизитлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнарыннан һәм жирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат турында мәгълүматлар:

- дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затының юридик затлар, шәхси эшмәкәрләрнең үзара эшләмәвенә контроле буенча чараларның йомгакларын анализлау, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарына, муниципаль контроль органнарына гражданнардан, шул исәптән, шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте, жирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларны карап тикшерү яки алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилле күрсәтмәсе реквизитлары;

- дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы житәкчесенең Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә чыгарылган приказы (боерыгы) реквизитлары;

- законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерүләр үткәрү турында прокурор таләбе реквизитлары һәм таләпләргә теркәлгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләрнең реквизитлары;

- юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара эшләмәүгә контроль буенча чаралар үткәрү барышында мәжбүри таләпләрнең бозылу куркынычы ачыкланган индикаторлар турында мәгълүматлар;

в) прокуратура органнары белән килешенеп үткәрелергә тиешле планнан тыш тикшерү үткәрү очрагында, зыян китерү яки таләпләр бозылу сәбәпле, әгәр алар шул моментка ачыкланса, чаралар күрү максатында, планнан тыш кучмә тикшерү кичектергесез үткәрелергә тиеш;

- тикшерү үткәрү турындагы боерыкка (приказга) вазыйфаи затның кимчелекне ачыклаган күрсәтмәсе теркәлгән документ (рапортлар, доклад язмасы һәм башкалар) күчермәсе реквизитлары

әлеге тикшерүнең бурычлары: ___

___

___

7. Әлеге тикшерүнең предметы (кирәклесен билгеләргә):

мәжбүри таләпләрне үтәү һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне үтәү;

аерым төрдәге эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турындагы хәбәрдә булган мәгълүматларның мәжбүри таләпләргә туры килүе;

юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, гражданнан аерым эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруга хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирүгә яки башка юридик әһәмиятле эшләр башкаруга рөхсәт (килешенү) алу турындагы гариза һәм документлардагы мәгълүматларның, юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гражданны тиешле планнан тыш тикшерү үткәрү хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирүгә яки башка юридик әһәмиятле эшләр башкаруга рөхсәт (килешенү) алу кагыйдәләрендә каралган, шулай ук күрсәтелгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр турындагы юридик

затларның бердәм дәүләт реестрындагы, шәхси эшмәкәрләр һәм башка федераль мәгълүмати ресурсларның дәүләт реестрындагы мәгълүматларына туры килүе;

дәүләт контроле (күзәтчелек) органнары, муниципаль контроль органнары күрсәтмәләрен үтәү;

түбәндәге чараларны үткәрү:

гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, милли китапханә фонды составына кертелгән аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия документларга зарар китерүне булдырмау буенча;

табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү буенча;

дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча;

андый төр зарар килүнең нәтиҗәләрен бетерү буенча.

8. Тикшерү үткәрүнең срогы: ________________________________

Тикшерү үткәрүгә «___» __________ 20___ елда керешергә.

Тикшерү үткәрүне «___» _____________ 20___ елдан соңга калмый тәгәлләргә.

9. Тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре: ________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

(тикшерү гамәлгә ашырыла торган норматив хокукый акт нигезләмәләренә сылтама)

10. Мәҗбүри таләпләр һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән, тикшерелергә тиешле таләпләр

________________________________________________________________

________________________________________________________________

11. Тикшерү процессында тикшерү үткәрүнең максатлары һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле контроль буенча түбәндәге чараларны үткәрергә (контроль буенча чара исемнәрен һәм аны үткәрү срокларын күрсәтеп):

1) ______________________________________________________________

2) ______________________________________________________________

12. Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәләрнең, дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне (булганда) гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар исемлеге:

________________________________________________________________

________________________________________________________________

(исемнәре, саннары һәм аларны кабул итү даталары күрсәтелә)

13. Тикшерү үткәрүнең максатлары һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле булган юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат күрсәтергә тиешле документлар исемлеге:

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

____________________________________________
____________________________________________ ________________________

(тикшерү үткәрү турында боерык яки приказ чыгарган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы житәкчесенең вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

(мөһер белән расланган имза)

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

боерык (приказ) проектын турыдан-туры әзерләгән вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) һәм вазыйфасы, элемтә телефоны, электрон адресы (булганда)

Административ регламентка
2 нче кушымта

Муниципаль контроль органы бланкында
«__» _____________ ел № ___
Яр Чаллы шәһәре

Вазыйфаи затның тикшерелә торган зат территориясенә
(бинасына) керүен тоткарлау турындагы
акт

Тикшерү үткәргәндә: ________________________________________________
________________________________________________________________,
(тикшерелә торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны адресы)
муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затның Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда гражданнарны тикшерүләр үткәрү буенча Административ регламентта билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр үткәрү турында хәбәр ителгән:
________________________________________________________________,
(тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларның Ф.И.А и., аларның вазыйфалары)
«__» __________ 20____ ел. № _________боерык нигезендә тикшерү үткәрү хокукына вәкаләтле зат тарафыннан тикшерелә торган затның _______ адресы буенча урнашкан территориясенә (бинасына) керү тоткарланды:
________________________________________________________________.
(өстәмә мәгълүмат күрсәтелә)

Тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлар:

| | |
|---|---|
| ______________________________ (вазыйфаи затның Ф.И.А.и.) | ____________________ (имза, дата) |
| ______________________________ (вазыйфаи затның Ф.И.А.и. ) | ____________________ (имза, дата) |

Гражданның (вәкаләтле вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

____________________
(имза, дата)

Административ регламентка
3 нче кушымта

______________________________________________________________
жирле үзидарә яки аның вәкаләтле органының исеме

______________________________________________________________
муниципаль торак контролен гамәлгә ашыра торган орган

______________________ ______________________
(акт төзү урыны) (акт төзү датасы)

______________________
(акт төзү вакыты)

Юридик затны, шәхси эшмәкәрне, физик затны муниципаль торак органы тарафыннан тикшерү актыь
№ ______

Адресы/адреслары буенча______________________________________________
(тикшерү үткәрү урыны)

нигезендә:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
(реквизитлары күрсәтелгән документның төре (саны, датасы))

______________________________ карата тикшерү үткәрелде:
(планлы/планнан тыш, документар/күчмә)

______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
(шәхси эшмәкәр, физик зат яки гражданның юридик типтагы исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

Тикшерү үткәрү датасы һәм вакыты:
«__» _____ _____ ел. __ сәг. __ минуттан ____ сәг. __ минутка кадәр. Дәвамлылыгы _______.
«__» _____ _____ ел. __ сәг. __ минуттан ____ сәг. __ минутка кадәр. Дәвамлылыгы _______.
(филиаллар, вәкиллекләр, юридик затның аерымланган структур бүлекчәләрен тикшергән очракта яки шәхси эшмәкәр берничә адрес буенча эшчәнлек алып барган очракта тутырыла)

Тикшерүнең гомуми дәвамлылыгы: ______________________________.
(эш көннәре/сәгатьләре)

Акт төзелгән:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
(дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы яки муниципаль контроль органы исеме)

Тикшерү үткәрү турындагы боерык/приказ күчермәсе белән таныштым (таныштык):
(күчмә тикшерү үткәргәндә тутырыла______________________________

______________________________________________________________

(фамилия, инициаллар, имза, дата, вакыты)

Тикшерү үткәрүне килешенү турында прокурор (аның урынбасары) карарының датасы һәм саны:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(тикшерүне прокуратура органнары белән килешенү кирәк булган очракта тутырыла)

Тикшерү үткәргән зат (лар):

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(тикшерү үткәргән вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) вазыйфасы; тикшерүдә катнашуга экспертлар, эксперт оешмалар җәлеп ителгән очракта экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) һәм (яки) эксперт оешмаларның исемнәре (аккредитация турындагы таныклык реквизитлары, аккредитация буенча таныклык биргән органның исеме күрсәтелә)

Тикшерү үткәргәндә катнаштылар:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(тикшерү буенча чаралар үткәргәндә катнашкан җитәкченең, башка вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) яки юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең вәкаләтле вәкиленең, үз-үзен көйли торган оешманың вәкаләтле вәкиленең (үз-үзен көйли торган оешма әгъзасын тикшергән очракта), физик затның яки гражданның яки аларның вәкиленең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (соңгысы – булганда), вазыйфалары)

Тикшерү үткәрү барышында:

Мәҗбүри таләпләрне яки муниципаль хокукый актларда (хокукый актлар нигезләмәләрен (норматив) күрсәтеп) билгеләнгән таләпләрне үтәүдә түбәндәге кимчелекләр ачыкланды:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(кимчелекләрнең характеры, аңа юл куйган затлар күрсәтелә)

эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы хәбәрдәге мәгълүматларның мәҗбүри таләпләргә (хокукый актлар нигезләмәләрен (норматив) күрсәтеп) туры килмәве ачыкланды:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнарының (бирелгән күрсәтмәләрнең реквизитларын күрсәтеп) күрсәтмәләрен үтәмәү фактлары ачыкланды:

______________________________________________________________

кимчелекләр ачыкланмады:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерү турында исәпкә алу журналына язып куелды (күчмә тикшерүләр вакытында тутырыла):

______________________ ____________________________________
(тикшерүче имзасы) (юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең имзасы)

______________________ ____________________________________
(тикшерүче имзасы) (юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең имзасы)

Актка түбәндәге документлар теркәлә: ____________________________________

Тикшерү үткәргән затларның имзалары:

______________________ ______________________
(имза)

Тикшерү акты белән таныштым, барлык кушымталары белән акт күчермәсен алдым:

________________________________________________________________

____________________________________
(житәкченең, башка вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) яки юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, физик затның яки гражданның яки аларның вәкиленең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (соңгысы – булганда), вазыйфалары)

«____» _______________ ______ ел. ______________
(дата) (имза)

Тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында билге:

______________________
(тикшерү үткәргән вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) имзасы)

Административ регламентка
4 кушымта

Муниципаль контроль органы бланкында

Тикшерелә торган затның
Ф.И.А.и.,
яшәү урыны адресы

Ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә
(мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар үткәрү)

«____» ____________________ ел. __________________________________.
(төзү датасы) (төзү урыны)

Күрсәтмә бирәм:

______________________________________________________________
(күрсәтмә бирелә торган тикшерелүченең Ф.И.А.и.)

| Т/с | Күрсәтмәнең эчтәлеге | Үтәү срогы | Нигезләү (норматив хокукый актка сылтама) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | | | |
| 2 | | | |

--------------------------------

<*> Күрсәтмә бирелгән зат, әлеге күрсәтмә пунктларының үтәлеше турындагы мәгълүматны муниципаль торак контроле органына күрсәтмәдә билгеләнгән срокта (срокларда) җибәрергә тиеш.

______________________ ______________ ______________________
(вазыйфаи затның исеме) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________ ______________ ______________________
(вазыйфаи затның исеме) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

М.У.

Күрсәтмә алынды:

______________________________ ______________ Дата
(тикшерелә торган затның яки
аның вәкаләтле вәкиленең Ф.И.А.и.
(ышаныч язуының номерын һәм датасын күрсәтү мәҗбүри)
(имза)

Административ регламентка
5 нче кушымта

## Муниципаль торак контроле буенча планлы тикшерүнең тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)

______________________________________________

(муниципаль контроль органы исеме)

нигезендә ______________________________________

(муниципаль контроль органы житәкчесе, житәкче урынбасарының тикшерү уткәрү турындагы боерыгының реквизитлары)

______________________________________________

(тикшерүнең исәп номеры һәм тикшерүләрнең бердәм реестрындагы тикшерүнең исәп номеры бирелү датасы)

______________________________________________

(планлы тикшерү уткәрә торган вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

______________________________________________

(юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

______________________________________________

(юридик зат/шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек төре, житештерү объекты, тибы, характеристикасы, куркыныч категория, куркынычлык классы)

______________________________________________

(тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү уткәрү урыны һәм (яки) юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан файдаланыла торган производство объектларын күрсәтү)

______________________________________________

(планлы тикшерү предметын тикшерү кәгазе формасында бәян ителгән мәжбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнгән таләпләрне, әгәр бу муниципаль контрольне оештыру тәртибе һәм уткәрү төрендә каралмаган булса, чикләүгә күрсәтү)

| Т/с | Сораулар | Мәҗбүри таләпләр билгеләнгән норматив хокукый актларның реквизитлары | Җавап вариантлары | |
|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк |
| 1 | Хокук бирә торган документларның булуы | РФ Торак кодексы 136 маддәсе 3 булеге, РФ Гражданлык кодексы 52 маддәсе 1,4 булекләре | | |
| 2 | Күп фатирлы йорт (лар) торак милекчеләренең гомуми җыелышында | РФ Торак кодексы 162 маддәсе 1 булеге | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | торак милекчеләренең беркетмә карары белән хуплаган, имзаланган күп фатирлы йорт (лар) белән идарә итү килешүе (ләре) булу | | | |
| 3 | Күп фатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге алып баруга лицензия булу | РФ Торак кодексының 192 маддәсе 1 бүлеге | | |
| 4 | Күп фатирлы йортның гомуми мөлкәтенә кергән конструкция һәм инженерлык җиһазларының техник торышын планлы карау үткәрү турында моны дәлилләүче документлар булу | РФ Торак кодексының 161 маддәсе 1, 1.1 бүлекләре | | |
| 5 | Күп фатирлы йортның гомуми мөлкәтен тиешенчә карап тоту буенча эшләр башкаруга документлар булу | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 3.2, 3.3 пунктлары, 3.4.8 пунктчалары, РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 3 апрелендәге 290 нчы карары белән расланган Күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару кагыйдәләренең 6,7,8,9 пунктлары | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6 | Торак фондын алдагы елда сезонлы эксплуатацияләүгә әзерләү һәм аны үтәү буенча чаралар планы | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.1.1 һәм 2.6.4 пунктчалары | | |
| 7 | Күп фатирлы йортларны кышкы чорда эксплуатацияләүгә әзерлек паспорты | Россия Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 нче приказы белән расланган Җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләренең 10 пункты, РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.6 пункты 2.6.10 пунктчасы | | |
| 8 | Күп фатирлы йорт торак милекчеләре каршында еллык хисап тотуның булуы | РФ Торак кодексының 162 маддәсе 11 бүлеге | | |
| 9 | Агымдагы елда торак фондының гомуми мөлкәтен агымдагы ремонтлау буенча план (эшләр исемлеге) | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кагыйдәләре һәм нормаларының 2.3 пункты 2.1.1, 2.1.5, 2.2.2 пунктчалары | | |
| 10 | Алдагы елда торак фондының гомуми мөлкәтен агымдагы ремонтлау һәм аны үтәү буенча план (эшләр исемлеге) | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.3 пункты 2.1.1, 2.1.5, 2.2.2 пунктчалары | | |
| 11 | Халыктан заявкалар кабул итү, аларны үтәү, контрольне гамәлгә ашыру, шул исәптән тәүлеклек авария хезмәте күрсәтүне оештыру документлары булу | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.2 пункты 2.2.3 пунктчалары | | |
| 12 | Торак милекчеләре ширкәте (ТСЖ) идарәсенең тикшерелә торган субъект уставында билгеләнгән вәкаләтләр срокларын үтәү | РФ Торак кодексының 147 маддәсе 2 бүлеге | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13 | Күп фатирлы йортның җылыту, су белән тәэмин итү, су бирү, гомуми мөлкәтне электр белән тәэмин итү системаларының техник торышы | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 5.2, 5.3, 5.6, 5.8 пунктлары, РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 3 апрелендәге 290 нчы карары белән расланган Күп фатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару кагыйдәләренең 17,18,19,20 пунктлары, 6 пункты | | |
| 14 | Контейнер мәйданчыкларын җыештыру графиклары булу | РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 3.7 пункты, 3.7.1 пунктчасы, «Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре һәм күп фатирлы йортлар белән идарә итү. Йорт яны территориясен карап тоту хезмәтләре, | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгару. Гомуми таләпләр» ГОСТ Р 56195-2014, 7.8 пункты | | |

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(исемлектәге сораулар буенча аңлатмалар һәм өстәмәләр)

Тикшерү үткәрүче затның имзасы:

______________________ ______________________

(фамилия, инициаллар)

Юридик зат житәкчесенең
(шәхси эшмәкәрнең) имзасы:

______________________ ______________________

юридик зат, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме,
атасының исеме (булганда)

Административ регламентка
6 нчы кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең блок-схемасы

Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендәге федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актларда муниципаль торак фондына карата билгеләнгән мәҗбүри таләпләр үтәлешен тикшерү үткәрү процедурасы башлану

↓

Тикшерү үткәрү турында муниципаль торак контроле органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) приказы

↓

Тикшерелә торган затның тикшерү үткәрү турындагы хәбәре

↓

Тикшерү процедурасын үткәрү

↓

Документлар һәм мәгълүматлар бирү турында запрос (таләп) буенча документлар һәм мәгълүматлар алу

↓

Тикшерү үткәрүнең срогын озайту

← юк

→ әйе

↓

Тикшерүне озайту турында боерык

↓

Тикшерүне тәгәлләү өчен кирәкле өстәмә чаралар үткәрү

↓

Тикшерү процедурасының тәмамлануы

↓

Тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзү

↓

Күрсәтмә бирү